ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮЗКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

19 апрель 2019 ел № 7

2018 ел өчен Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү хакында

Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге халкының «2018 ел өчен Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында карар проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатыннан, 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ санлы Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «2018 ел өчен Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Советы карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегендә мәгълүмати стендларда һәм Тукай муниципаль районның рәсми сайтында 2019 елның 26 апреленнән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

3. Билгеләргә

- үткәрү срогын – 1 көн;
- үткәрү вакытын – 2019 елның 29 апрелендә 10.00 сәгатьтә;
- үткәрү урынын – Күзкәй авылы, Ахметшин урамы, 18 йорт (Күзкәй Башкарма комитеты бинасы, утырышлар залы);
- фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим итү, чыгыш хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү адресын – Күзкәй авылы, Ахметшин урамы, 18 йорт (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатька кадәр);
- чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү вакыты – 2019 елның 29 апреленә кадәр.

4. Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Башкарма комитетына билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда «2018 ел өчен Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында карар проекты буенча халык тыңлауларын әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Күзкәй авыл җирлеге Башлыгы Э.Р Гәрәев